САВРУШСКОның АКСУБАЕВС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫ СЕЛЬ ПОСЕЛЕНИЯСЕ КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**№21** **от 23.12.2019 г**

"Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2018 елның 24 декабрендәге 14 номерлы Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Аксубай муниципаль районының Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты ПОСТАНОВЕТ:

1. "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Савруш авыл жирлеге башкарма комитеты карарының 4 нче кушымтасында түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.5 пунктының 3 абзацында**: планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы» сүзләрен «урам-юл челтәре элементы һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда) исеме» сүзләренә алмаштырырга;

**1.5 пунктның 5 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, жир кишәрлеге яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет житәкчесе Саврушский комитеты авыл җирлеге: А.Г.Кузьмин